СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район,
422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш
авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№ 6**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылында Ташкичү авылы, Ленин урамы, 53 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе бу-

енча 2025 елның 25 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенынын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Ленин, Нариман урамнары) ;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу, ут челтәрләрен төзекләндерү);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (зиратны тоту өчен җиһазлар сатып алу: бензин белән эшләүче чапкыч – 1 данә, диска – 1 данә);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агачларны кисү);

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне тәртипкә китерү (Ленин урамынын коесын төзекләндерү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына ТР, Арча районы, Ташкичү авылы, Ленин урамы, 53 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин